

Әгүзү билләһи минәш-шәйтанир-раҗим.
Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.
Үз исемемнән һәм авыл халкы исеменнән, Сезне, хөрмәтле Альта Хаҗи кызы, олуг бәйрәмегез – 80 яшьлек юбилеегыз белән котлыйбыз.
Коръәни Кәримдә: “Аллаһуның сәламе туган көнеңдә, үлгән көнеңдә, кабердән кубарылган чагында”(19-33), ягъни, Аллаһуның рәхмәтенә ирешәчәк шул, кем гомерен Аллаһ риза булырлык – биргән нигъмәтләренә канәгать булган, кушканнарны җиренә җиткереп үтәгән, тыйганнарыннан тыелган - тәкъдиренә риза булучы.
Пәйгамбәребез (с.в.г.)нән бер кеше сорады:”Әй, Аллаһның илчесе, иң хәерле кеше кем була?” Пәйгамбәребез (с.в.г.) әйтте: “Кемнең гомере озын һәм гамәле яхшы – шул.”
Һәрбер кешенең гомере кыска бер мизгел. Шул мизгелләр авылыбызның, республиканың, илебезнең тарихы белән бәйләнгән.
Хәтерләрдә саклана – әби-бабаларыбызның игенчелек белән шөгыльләре, күп балалы гаиләләр булу, аларны үз нигезләре янында йорт төзеп башка чыгару, гражданнар сугышы, революция еллары. Күмәк хуҗалыклар оештыру яңа бер чор булып тора. Бер яктан хәлле крестьян халкын чит җирләргә сөрсәләр, икенче яктан – халыкка гыйлем бирү өчен мәктәпләр төзелгән, авылларга техника кайта башлаган. Халыкның хәле җиңеләя башлаган чакта яңадан Икенче Бөтендөнья сугышы башланган. Фронтта хәлләр авыр була, тылда да җиңел түгел – ачлыктан һәм чирдән халык кырыла.
Сез дә шул сугыш чоры баласы. Авыл мәктәбендә җыелган яңа коллектив төрле буын вәкилләренә гыйлем бирә башлый. Шул чорда төрле өлкәләрдә эшләргә сәләтле галимнәр чыктылар. Шушы зыялылар арасыннан менә Сез дә,

яшьлек хыялыгызны тормышка ашырып, халкыбызның , авылыбызның тарихын барлап безгә җиткердегез. Зур рәхмәт хезмәтегез өчен.
Сезгә исәнлек-саулык телибез. Сездән бөркелгән нурдан, килгән җылылыктан кешеләр рәхәтлек, җаннарына тынычлык, авыруларына шифа тапсын. Хөрмәт белән туганың Мансур хәзрәт.